«Кулыма калəм күтəрəп...»

«Халыкны юк итим дисəң, иң беренче чиратта, аның тарихын, əдəбиятын, динен чагылдырган язма мирасыннан башларга кирəк», — диләр. Чыннан да, бу сүзләрдə хаклык бар. Узган гасырның «совет халкы» ясалып килгəн бер чорында, халкыбыз динен генə түгел, үз тарихын, əдəби ядкарьлəрен дə югалта язды. Моннан үзгəртеп коруга ялганып киткəн милләт аңы уяну һəм милли хəрəкəтнең башлануы гына саклап калды. Ләкин күбебез өчен, əле бүген дə, инкыйлабкача чор куе томан эчендə кала бирə. Əлифба үзгəрү дə күп кенə кыенлыклар өсти. Кемнəрдер махсус, кемнəрдер үзləре дə сизмəстəн ата-бабаларын, нəсел-нəсəбен онытты. Əле узган гасыр башында гына исемнəре дан-шөһрəт эчендə йөзгəн, хөрмəт казанган шəхесləребезнең күбесе бүгенге көндə онытылып, тарих тузанына чорналып, Каф тавы артында калды. Шуларның берсе — Мотыйгулла хəзрəт. Җырчы, журналист, «Əл-Гасрел-җəдид», «Уклар» журналларын, «Фикер», «Уралец» газеталарын чыгаручы Камил Мотыйгый һəм артист, җырчы Галия Кайбицкаяларның əтисе, шагыйрь Габдулла Тукайның остазы булган шəхес кем соң ул?

Моңарчы дөнья күргəн əдəбиятка таянып без Мотыйгулла Төхфəтулла улының Казан губернасы Зөя өязе Кече Кайбыч авылында* 1845 (яисə 1846) елны мулла гаиләсендə туып, бик яшьли ятим калуын һəм авыл кешеləренең бу зиһенле баланы Кышкар авылы мəдрəсəсенə** укырга җибəрүləрен белə идек.

Кызык, ə шул чор документлары бу хакта ни сөйли икəн? Татарстан Республикасы Милли архивында сакланучы 9нчы[1] (1850 ел) һəм 10нчы[2] (1858 ел) ревизия материалларына мөрəҗəгать итеп, кызыклы фактларга юлыктык. Мотыйгулла Төхфəтулла улы 1844 елның ноябрь аенда дөньяга килгəн[3]. Ə 1858 елгы материаллага караганда «Мотыйгуллага 13 яшь. Əтисе — Төхфəтулла Нигъмəтулла улына — 50. Аның беренче хатыны Сəрвиҗамал***

* Бүгенге көндə бу авыл Татарстанның Апас районына керə.
** Бүгенге көндə бу авыл Татарстанның Арча районына керə. Кышкар мəдрəсəсе XIX-XX йөз башында мəшһүр мəдрəсəлəрнең берсе булган.
*** Ревизия материалларында: «Сарфизямал».

Минкинага (Мотыйгулла хәзрәтнең әнисе. — *Р. Г.*) — 49, икенчесе — Хөббениса Мөстәкыймовага — 41 яшь һәм беренче хатыныннан — өч ул, ике кыз, икенчесеннән — бер ул һәм өч кыз» булуы ачыкланды[4].

Эзләнгән саен ак таплар артып, ачыкланасы сораулар өстәлә тора. Киләчәктә Г. Тукай иҗатын өйрәнүче галимнәребез, аның укытучысы һәм тәрбиячеләренең берсе булган, данлыклы «Мотыйгыя» мәдрәсәсенә нигез салган Мотыйгулла хәзрәтнең эшчәнлегенә дә күз салырлар дип ышанасы килә. К. Мотыгый да бит әтисенең гыйльме гаруз* дәресләрен алып баруын һәм Г. Тукайның шигырь турында беренче белемне Мотыйгулла Төхфәтуллиннан алуын яза. Бөек шагыйребезнең иҗат башлангычында «адәм аңламаслык тел» белән язуы да Каһирәдә белем алган остазы йогынтысы түгел микән?

1867 нче елда Кышкар мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң, гыйлемгә хирыс Мотыйгулла, XIX йөзнең икенче ярты-сында ислам дөньясының гыйлем учагына әверелгән Мисырның «әл-Әзһәр» университетына укырга китә һәм 1868-1874 елларда шул уку йортында белем ала[5]. Укып кайткач, Җаек (Уральски) шәһәрендә кияүдә булган апасында туктала. Каһирәдә белем алган бу егетнең укымышлылыгын күргән мәхәллә кешеләре Түбән оч мәчетенә мулла булып калуын сорыйлар. Мотыйгулла хәзрәт Җаек шәһәре мәчетендә мулла булу белән беррәттән XIX йөзнең 70 еллар ахырында «Мотыйгыя» мәдрәсәсенә дә нигез сала. Бу уку йорты XX йөз башында, нигездә, кадими мәдрәсә саналса да, өлешчә генә уку-укыту реформасы үткәрелеп, башкалардан хәр фикерлелеге белән аерылып торган. Габдулла Кариев: «Дамелла Мотыйгулла хәзрәт Мисырда укыган бер галим фазыйль кеше булганлыктан, алар мәдрәсәсендә башка мәдрәсәләрдәге кебек вак-тояк кысынкылыклар булмый иде. Ул заманда иң хәр мәдрәсә алар мәдрәсәсе иде»[6], — дип искә ала. Әлеге уку йортының тарихы ныклап тикшерелмәгән. Кадими дип исәпләнгән мәдрәсәнең җитәкчесе дә шул ук кадими карашта булырга тиеш ләбаса. Ләкин Мотыйгулла хәзрәтнең үз балалары — Камил Мотыйгый һәм Галия Кайбицкаяларны гына телгә алсак та, аларның үз чоры өчен алдынгы карашлы, җәмгыятьнең үзәгендә кайнаучы шәхесләр икәнен күрәбез.

Мотыйгулла хәзрәт белән Гыйзенас абыстайның барлыгы унбиш балалары булып, җидесе сабый вакытында вафат була. К. Мотыйгый белән Г. Кайбицкаяга өстәп тагын бер баласын — мәгърифәтчелек рухында язучы шагыйрә Әминә Мотыйгулла кызы Төхфәтуллинаны да атап китәргә мөмкин. Октябрь инкыйлабына кадәр чыгып килгән «Сөембикә» журналы битләрендә аның шигырьләрен күрергә мөмкин.

М. Төхфәтуллин ир балалар белән беррәттән кыз балалар өчен дә мәктәп ачучы кеше. «Вакыт» газетасы битләрендә «Уральскида ахун Мотыйгулла хәзрәт йортында яңа «Кызлар мәктәбе» ачылачактыр. Мөдире Мотыйгулла хәзрәт үзе булып, укыту 10 сентябрьдән майның ахырына кадәр дәвам итәчәктер»[7], — дигән хәбәргә тап булдык. Кызганычка каршы, әлеге мәктәп ачылганмы, анда кемнәр белем алган — аныcы караңгы булып кала бирә.

XX йөз башында атаклы дип саналган мәктәп-мәдрәсәләребезнең (бигрәк тә Татарстан җирлегендә булганнарының) тарихы, аларның җитәкчеләре һәм матди ярдәм күрсәтүчеләренең эшчәнлеге өйрәнелеп, киң катлау җәмәгатьчелеккә җиткерелде инде. Татарстаннан читтә булган күп кенә уку йортларыбыз, мөгаллимнәребез, аларның хезмәтләре исә бүгенгә кадәр ныклап өйрәнелмәгән. Әлеге кечкенә генә хезмәтебез мулла, ахун һәм мөдәррис Мотыйгулла хәзрәт Төхфәтуллинның тормышына бераз ачыклык кертер дигән теләктә калабыз. Аның «Шура» журналы һәм «Вакыт» газетасы битләрендә дөнья күргән, дин гыйлеме мәсьәләләренә багышланган берничә мәкаләсе бар. Шуларның берсен, күтәрелгән мәсьәләнең бүгенге көндә дә актуаль булуы сәбәпле, укучыларга тәкъдим итәбез. Мәкалә безнең тарафтан кыскартылып, текстологик яктан эшкәртелеп бастырыла.

* Гыйльме гаруз — шигырь төзелеше турында белем.

ИСКӘРМӘЛӘР:
1. ТР МА, 3 ф., 2 тасв., 219 эш.
2. Шунда ук, 353 эш.
3. Шунда ук, 261 кгз.
4. Шунда ук, 353 эш, 502 кәгазьнең арткы ягы – 503 кгз.
5. Коръәне Кәрим тәрҗемәсе хакында // Шура. – 1912. – № 10. – Б. 293.
6. Кариев Г. Габдулла Тукаевның Уральскидагы тормышы // Тукай турында хәтирәләр. – Казан, 1976. – Б. 43.
7. Дахили хәбәрләр // Вакыт. – 1907. – № 216.

Коръәне Кәрим тәрҗемәсе хакында

Коръәне Кәрим тәрҗемәсе хакында төрле газеталарда төрле мәкаләләргә тәсадеф иттекемнән, кәндемә тәрҗемә тарафдары идекемне белдерүдән катгы нәзар, тәрҗеməи Коръәннең лөзүмен бәян тарзында, кулыма каләм күтәреп, түбәндәге сүзләремне язмая ибтидар әйләдем. «Әл-Коръән» кяффәи мөселманнарның иман килтермеш, мөкаддәс китаплары улдыгыннан, жәнабе рисаләтпәнаһ әфәндемездә кяффәи әбнаи бәшәргә рәсүл улдыгыннан, бөтен җир йөзендә ничә-ничә биң лисаннар кулландыгыннан, [...] Казан татар-төрекләре, рус, инглиз, франса, америка, һинд, фарис вә башка лисаннара улсын, тәрҗемә ителеп, безләрә «Коръән» нә әмер итә вә нәдән нәһи итә, нинди мәгарифкә кызыктыра, вә нинди дога-вәгазь нәсыйхәт итә, нинди әхсәнел-кыйсаслар, вә нинди тарихе мөкаддәсләр бәян итә, шунларны бер-бер тәфсыйләп Коръән васитасы илә һәрбер әфраде мөэмин-мөселманнарга белмәк фарыздыр.

Үйлә исә, кяффәи бәни бәшәрнең үз лисаннарына тәрҗемә ителмәктә китабымыз Мөкаддәс Коръәннең мәгънәи шәрифене һич тә аңламаеп йөрмәкемез, әлбәттә, безем бәдбәхетлектән наши бөек гаеп вә бөек рәзаләт улмакында кем тәрәддет вә кем шөбһәләр итәр?..

Вәл-халәте һазиһи безем фазыйле мөхтәрәм Муса әфәнде Жарулла һәм дә Зыя әфәнде әл-Камалиләр тарафыннан татарчага Коръән тәрҗемә ителәчәк дия, хәбәрләр ишетелектә безем [...] такырлар «Коръәннең мәгънәсен белү нигә кирәк?» — дигән кеби Коръән тәрҗемә ителмәсен вә аны басарга рөхсәт бирелмәсен дия, галәл-гомйа жаһиланә вә дәлилсез каршы торганнары ишетелде вә күрелде.

Жәнабе рәсүл һәр көррәт әрыздагы бәни бәшәргә пәйгамбәр ителеп жибәрелмеш улдыгыннан һәр кангы милләт улса улсын, Китабе Мөкаддәс тәрҗемә ителдектә мәгънәи Коръәнне аңлап, пәйгамбәрнең Коръән илә күстәргән хөкемнәренә төшенер, васыяте нөбүвәт тә анлара васыйль улмыш улып, пәйгамбәре зи-шаны тәсдыйк вә икърар итәрләр һәм итмәктәләр.

Коръән могжизаи баһирә улдыгыннан пәйгамбәрләремез хаклыгына олуг дәлил вә борһане әкбәрдер. Фәкать мәгънәсе белмәян әлфаз кангы кавемгә нисбәт илә улса да, диз-биз-жәсәкъ-бәсәкъ кабиленнән белемсез бер сада улыр. Шуның өчен улса кирәк, күп вакытта татар-төрекләремез Коръән укылдыкта хур-хур йоклап, мыш-мыш калка-калка дыңламакталар. Әмма Гарәбестанда бам-башка.

Бән кәндем: әл-Каһирәдә жамигыль-Әзһәрдә алты сәнә тәрбия ителдекем әснасында гарәпләрнең Коръән укылдыкта тыңламакларын, гаять нәшатлы сурәттә күреп, тәгажжептә калыр булдым. Вакыф сәктәләрендә дыңлаучылар бер агыздан жәһрән исме Илаһи тәкрарлап кари әфәндея алкышлап торалар, бәгъзан дәһшәтле аятьләр укылдыкта [...] кәлимәи тәүхид ижра итәрләр. Бу нидән бөйлә? Әлбәттә, Коръәне Шәрифнең мәгънәсен һәр кеше аңлаганлыктандыр.

Коръән укылдыкы мәжлесләрдә берничә аять укылдыкы кеби, галәл-фәвер кари әфәнде шу аятьләрнең тәрҗемәсендә татар абзыйларына укып бирмәк лязимдер. Бу тәкъдирдә әһалие мәжлес әсраре Коръәннән бераз хәбәрдар улыр иде. Ләкин әксәре муллалар үзләре дә мәгънәи Коръәннән хәбәрдар дәгелләр.

Бәгъзе тарафтан язылмыш мәкаләләргә караганда: гүя безләр Коръән тәрҗемәсене белмәк илә мөкәлләф дәгелмез имеш. Бу сүзләр һич тәслим кылыначак сүз дәгелдер. Рәсүле әкрәм анчак гарәпләргә генә килмәмештер, аның илә жибәрелмеш Китабе Мөкад-

дәс гарәби лисандыр, бу казыя үз-үзенә, тәрҗемәи Коръән фарыз идекене нәтиҗә вирер кыястыр.

Сәйиде кяинат әфәндемезнең кайсар, малике Фариска вә гайреләргә язган мөбарәк мәктүпләре гарәби иде. Мәгълүм ки, кайсаре Рум — гарәп дәгел. Малике Фарис кисраи Фарис иде. [...] Әлбәттә, тәрҗемәсе үзләренә лязим идекен белдермеш. Ушандак: Коръән тәрҗемәсе безем үземезә хәвалә иделмештер. Тәрҗемәсез без татар-төрекләре нә асыл аңлаялым. Нә асыл гыйбадәт идәчәкмез, нинди хөкемнәр беләчәкмез? [...]

Бәгъзеләр яза: «Тәфсирләр бик күп», — дип. [...] Ләкин гарәби тәфсирләр, Коръәннең үзеннән әллә никадәр агыр улып, төрле фәннәргә кереп киткәннәр: тәфсирләрендә нәхү сөйләп, мантыйк сөйләп [...] максаттан ерак китеп, тәрҗемәи Коръәнне эзләп табып булмас дәрәҗәсенә илтеп куйганнар, чар-начар мәгънәи Коръән беленмәй шул көенчә калуга сәбәп улмышлардыр.

Безем Коръән татар-төрекләре тарафыннан тәртип иделмешләре дә, ниһаять дәрәҗәдә мөкаллидлекләреннән, Коръәне Шәрифтә һич юк сүзләрне, мәгънәсе арасына кушып бардыкларыннан пәк тә рәваҗле дәгелләрдер.

Хәзерге мәйданга чыгачак дия көтеп тордыкымыз тәрҗемә лисане гарәбийе ана лисаннары кеби билән зәвате мөхтәрәмәләр: фазыйль Муса Җарулла, Зыя әл-Камали әфәнделәр тарафыннан чыкдыкыннан өметемездер ки, иншаллаһ, тәрҗемә, вә ие тәрҗеməи Коръән, улыр. Җан вә дилдән, бер көн әүвәл чыксалар иде дия, хәтме кәлям итәм.

Уральски шәһәрендә сабикъ ахунд мулла Мотыйгулла Төхфәтуллин.

Шура. – 1912. – № 10. – Б. 293.

СҮЗЛЕК:

Әбнаи бәшәр — барча кешеләр.
Әксәр — күпчелек.
Әлфаз — сүзләр.
Әсраре Коръән — Коръән серләре.
Әфрад — кешеләр.
Әхсәнел-кыйсаслар — гүзәл хикәяләр.
Әһалие мәҗлес — мәҗлестә катнашучылар.
Бам-башка — бөтенләй башка.
Бәгъзе — кайбер.
Бәдбәхетлектән наши — бәхетсезлек аркасында.
Бән кәндем — мин үзем.
Белдерүдән катгы нәзар — белдерүдән башка.
Биң — мең.
Борһане әкбәр — ышандыру өчен китерелгән иң зур дәлил.
Вакыф сәктәләре — Коръән укылганда билгеле урыннарда тотылырга тиешле паузалар.
Васыйль улу — ирешү.
Васыяте нөбүвәт — пәйгамбәрлек.
Вәл-халәте һазиһи — хәзерге вакытта.
Галәл-гомйа — сукырларча.
Галәл-фәвер — ашыгычлык белән, ашыгып.
Дил — күңел.
Җәнабе рисаләтпәнаһ әфәндемез — пәйгамбәребез.
Җәһрән — кычкырып.
Зәват — затлар.
Зи-шан — шанлы, данлыклы.
Ибтидар итү — (берәр эшкә) керешү.
Ие тәрҗемә — яхшы тәрҗемә.
Ижра итү — үтәү, башкару.
Казыя — мәсьәлә.
Кайсар — император.

Кангы — кайсы.
Кари — укучы.
Кәлимәи тәүхид — «Ләә иләһә иллә-ллаһ» дип әйтү.
Кисра — исламга кадәр Иран хөкемдарларының гарәби титулы.
Китабе Мөкаддәс — Коръән.
Коръән васитасы илә — Коръән аша.
Көррәте әрыз — җир шары.
Күстәрү — күрсәтү.
Кыяс — мисал.
Кяффә — бөтен.
Лисан — тел.
Лөзүм — кирәклек, тиешлек.
Лязим — тиеш.
Малике Фарис — Фарсы дәүләтенең җитәкчесе.
Могҗизаи баһирә — ачык күренеп торган (шиксез) мозҗиза.
Мөкаддәс — изге, бөек.
Мөкаллидлек — иярүчелек.
Мөкәлләф — йөкләтелгән.
Нә асыл — ничек.
Нәхү — биредә: гарәп теле синтаксисы.
Нәһи итү — тыю.
Нәшатлы — актив.
Рәваҗле дәгелләр — таралмаганнар.
Рәзаләт — хурлык, түбәнлек.
Рәсүле әкрәм — Мөхәммәд пәйгамбәр.
Сабикъ — әүвәлге.
Сада — тавыш.
Сәйид кяинат әфәндемез — пәйгамбәребез.
Тәрәддет — икеләнү.
Тәсадеф итү — очрату.
Тәфсыйль — тәфсыйльләп аңлату.
Фазыйль — игелекле, укымышлы.
Хәвалә итү — тапшыру.
Чар-начар — теләсә дә, теләмәсә дә.

Текстны басмага
тарих фәннәре кандидаты
Рафилә Гыймазова
әзерләде

РЕЗЮМЕ
Публикация кандидата исторических наук Р. Гимазовой, основанная на документах НА РТ, содержит малоизвестные факты биографии Мутыгуллы Тухватуллина — основателя медресе «Мутыгия» в г. Уральске в середине XIX в.